**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 19 июнендәге 2573 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Совет районында Школьная урамы буенча ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган гавами сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 1985 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган кварталның кадастр номерлары: 16:16:120126, 16:16:000000;
- урнашу урыны: Школьная урамы, Совет районы, Казан шәһәре;
- билгеләү максаты: җир кишәрлеге аша үтеп чыгу яисә транспорт белән үтү, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектына һәм аның яр полосасына ирекле керүен тәэмин итү максатларында;
- билгеләү чоры: 2 ел;

1.2. гариза бирүче: «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе;

1.3. билгеләү нигезләре: гариза бирүченең мөрәҗәгате, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 26 декабрендәге 4628 номерлы «Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Совет районында Константиновка торак массивында Школьная урамы буйлап автомобиль юлын реконструкцияләү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында» карары.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге

чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнары рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма


комитетының 2024 елның

19 июнендәге 2573 номерлы

карары белән расланган

1 номерлы кушымта

**Школьная урамы буенча кадастр кварталы территориясенең бер өлешенә ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштабы 1:500

| | |
|---|---|
| Координаталар системасы: МСК-16 | |
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:16:120126, 16:16:000000 | кадастр кварталы |